| СОВЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | | **КАРАР** |
| 12.05.2023 | п.г.т. Алексеевское | № 70 |

**Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 13.12.2022 ел, №62 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск шәһәр җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьяларына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, 2023 елның 25 гыйнварындагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып,

**Алексеевск шәһәр җирлеге Советы карар итте:**

1. Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге Советының 13.12.2022 ел, № 62 карары белән расланган Алексеевск шәһәр тибындагы бистәсендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләренең  шәһәр төзелеше зоналаштыру картасында үзгәртергә:

Алексеевск шәһәр тибындагы бистәнең көнбатыш өлешендә Ж1-П территориаль зонасы һәм Ж-1 территориаль зонасының бер өлеше (Индивидуаль торак төзелеш зонасы) ОД 1-3 территориаль зонасына (күп функцияле җәмгыявиэшлекле зона) үзгәртелде.

Әлеге территориаль зонаны үз эченә алган җир участогының кадастр номеры: 16:05:011501:358

Әлеге территориаль зонаның урнашуының кадастр кварталы: 16:05:011501

Ж1-п территориаль зонасы һәм Ж1 территориаль зонасының бер өлеше ОД 1-3 зонасына үзгәрде.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында,«Федераль дәүләт территориаль планлаштыру мәгълүмат системасы» (https://fgis-tp.ru) рәсми сайтында   һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/)бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы урынбасары В. В. Увакинага йөкләргә.

**Алексеевск шәһәр җирлеге Башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С. А. Демидов**

Алексеевск шәһәр җирлеге
Советының 12.05.2023ел,
№ 70 карарына 1 нче кушымта




